**Казан шәһәре Думасының**
**2025 елның 14 маендагы 7-38 номерлы карары**

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә махсус билгеләнештәге яшелләндерү ярдәмче зонасы (ОСН) чикләрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 46 статьясы, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 20 февралендәге 583 номерлы «Казан шәһәре Думасының Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә махсус билгеләнештәге яшелләндерү ярдәмче зонасы (ОСН) чикләрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын әзерләү хакында»гы карары, «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 2023 елның 10 гыйнварындагы 103/15-2 КТ ДСП номерлы хаты нигезендә һәм 2025 елның 16 гыйнварыннан алып 2025 елның 30 гыйнварына кадәр уздырылган җәмәгатьчелек белән фикер алышулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Казан шәһәре Думасы **карар бирде:**


1. Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: урам-юл челтәре, табигать-рекреация комплексы, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында әлеге карарга кушымта нигезендә территориаль зоналарның – махсус билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасының (С3) (93 номерлы контур), шәхси һәм блоклы торак төзелеше зонасының (Ж1) (46 номерлы контур, 147 номерлы контур), табигать территорияләре зонасының (Р1) (15 номерлы контур), махсус билгеләнештәге яшелләндерү зонасының (ПР) (25 номерлы контур) махсус билгеләнештәге яшелләндерү ярдәмче зонасы (ОСН) чикләрен үзгәртергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының
2025 елның 14 маендагы
7-38 номерлы карарына кушымта

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составындагы территориаль зоналарның урам-юл челтәре, табигать-рекреация комплексы, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы фрагменты**




**Шартлы билгеләр:**

**Ж1 - 46**

Территориаль зона контурының тәртип номеры

Территориаль зона индексы

**Территориаль зона**

| **Төс** | **Индекс** | **Территориаль зона төренең атамасы** |
|---|---|---|
| | Р1 | Табигать территорияләре зонасы |
| | ПР | Махсус билгеләнештәге яшелләндерү зонасы |
| | С3 | Махсус билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасы |
| | Ж1 | Шәхси һәм блоклап төзелгән торак төзелеше зонасы |

**Территориаль зоналарның ярдәмче зоналары**

| **Төс** | **Индекс** | **Территориаль зонаның ярдәмче зонасы төре атамасы** |
|---|---|---|
| | | Махсус билгеләнештәге яшелләндерүнең ярдәмче зонасы |
| | | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: урам-юл челтәре, табигать-рекреация комплексы, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы фрагменты чиге |

**Башлыкның беренче урынбасары** **Д.Г.Калинкин**